ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ
ул. Карима Тинчурина, д. 29, г. Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ
К. Тинчурин ур., 29 йорт, Казан шәһәре, 420021

Телефон: (843)211-66-94, факс: (843)211-66-47, E-Mail:ojm@tatar.ru, сайт:http://ojm.tatarstan.ru

Приказ  Казан шәһәре  Боерык

29.11.2022  № 400- од

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2021 елның 11 февралендәге 40-од номерлы боерыгы белән расланган Тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча эшне камилләштерү максатларында боерам:

1. Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2021 елның 11 февралендәге 40-од номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2021 елның 03 ноябрендәге 340-од номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган Тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте

күрсәтүнең административ регламентына, яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (кушымта итеп бирелә).

2. Рәис урынбасарларына, структур бүлекчәләр җитәкчеләренә, дәүләт хезмәтләре күрсәтүне турыдан-туры тәэмин итүче затларга регламентларның нигезләмәләрен үтәүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Рәис вазыйфаларын башкаручы Ю.Б. Матвеев

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2021 елның 11 февралендәге 40-од номерлы боерыгы белән расланган
(Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2022 елның 29 ноябрендәге 400-од номерлы боерыгы редакциясендә)

# Тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты(алга таба – Регламент) тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү буенча карар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Гариза бирүчеләр: рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралларны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне ирекле рәвештә тапшырган 18 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк гражданнар (алга таба – гариза бирүче).

Гариза бирүче исеменнән ышаныч кәгазе һәм аның шәхесен раслый торган документлар нигезендә ул вәкаләт биргән физик зат эш итә ала.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә (хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан үткәрелә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән гариза бирүченең билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү) профильләштерү үткәрелми.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте атамасы.

Тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган исеме.

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Комитет).

Дәүләт хезмәте Комитетның административ һәм суд практикасы бүлеге (алга таба – Бүлек) тарафыннан күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» Дәүләт бюджет учреждениесе һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең (алга таба – КФҮ) ерактагы эш урыны аша күрсәтелә.

КФҮгә дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап гариза биргән очракта, КФҮнең гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итү мөмкинлеге бар.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

Тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү (алга таба – акчалата бүләкләү) билгеләү һәм түләү турында карар (тәкъдим ителә торган форма әлеге Регламентка 1 нче кушымтада китерелгән);

акчалата бүләкләү түләүдән баш тарту турында карар (тәкъдим ителә торган форма әлеге Регламентка 2 нче кушымтада китерелгән).

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе гариза бирүчегә үзе сайлаган ысул нигезендә бирелә (җибәрелә) :

гариза бирүчегә шәхсән язма рәвештә яки почта аша җибәреп;

Комитетның вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә имзаланган электрон документ рәвешендә электрон почта адресына яисә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы гариза бирүченең шәхси кабинетына (http://uslugi.tatarstan.ru) (алга таба – Республика порталы). Гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен алу башка мәгълүмати системаларда теркәлми.

Гариза бирүченең теләге буенча дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе шулай ук КФҮ дә КФҮ хезмәткәре мөһере һәм имзасы белән таныкланган кәгазьдә басылган электрон документ нөсхәсе рәвешендә бирелә.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар гариза бирүче тарафыннан шәхсән яисә почта аша тапшырылган булса, дәүләт хезмәте әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар Комитетта теркәлгән көннән алып өч ай эчендә бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Республика порталындагы шәхси кабинет аша тапшырылган очракта, дәүләт хезмәте гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә номер бирелгәннән һәм Республика порталындагы шәхси кабинетта чагылдырыла торган «Документларны тикшерү» статусы нигезендә өч ай эчендә бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар КФҮгә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар КФҮгә ташырылганнан алып өч ай эчендә бирелә.

Гариза бирүчегә акчалата бүләк түләү тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-ракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү түләүләрне оештыру комиссиясе (алга таба – Комиссия) карар кабул иткән көннән алып 30 эш көне эчендә башкарыла.

Акчалата бүләкләүне билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) карар җибәрү аны кабул иткән көннән алып 10 эш көне эчендә башкарыла.

Гариза бирүче КФҮгә мөрәҗәгать иткәндә, гариза һәм беркетелә торган документларны Комитетка Комитет белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда тапшыру тәэмин ителә. акчалата бүләк түләү (түләүдән баш тарту турында) турында карар кабул итү процедурасын гамәлгә ашыру вакытына гаризаның КФҮдә булу вакыты һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсен Комитеттан КФҮгә тапшыру вакыты кертелми.

Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе гамәлдә булу срогы дәвамында электрон документ рәвешендә акчалата бүләкләүне билгеләү һәм түләү (түләүдән баш тарту турында) турында карар алырга хокуклы.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр.

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләр) бердәм порталында (http://gosuslugi.ru ) (алга таба – Бердәм портал), республика Порталында түбәндәгеләр урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрнең, эшчеләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге.

2.6.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, гариза бирүче мөстәкыйль тапшыра торган документлар:

1. Акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү турында гариза (әлеге Регламентка 3 нче кушымта).

2. Акчалата бүләкне билгеләү һәм түләү турындагы гаризага түбәндәге документларны беркетергә кирәк:

1) шәхесне раслый торган документның күчермәләре;

2) корал, хәрби кирәк-яраклар, коралга патроннар, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләр кабул итү турында Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәте Идарәсенең яки Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары тарафыннан бирелә торган квитанция;

3) Россия Федерациясе Үзәк банкы яисә кредит оешмасы учреждениесендә ачылган, акчалата бүләкләү күчереләчәк счет реквизитларын үз эченә алган документ.

Гариза һәм беркетеп бирелә торган документлар гариза бирүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсен кулланып җибәрелергә мөмкин:

1) Комитетка шәхсән яисә почта аша кәгазьдә һәм 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китереп имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә.

2) КФҮ аша кәгазьдә һәм 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китереп имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә.

Гариза биргәндә, гаризаның җибәрелүен раслый торган теркәлү номеры һәм электрон гариза бирү датасы булган КФҮ дән расписка бирелә;

3) Республика порталы аша электрон формада.

Гаризаны Республика порталы аша җибәргәндә, гариза бирүче гариза биргән көнне Республика порталындагы шәхси кабинетына һәм электрон почта аша гаризаның теркәлү номеры һәм гариза бирү датасы күрсәтелгән, гариза җибәрелүен раслый торган хәбәрнамә ала.

Гариза һәм кирәкле документларны Республика порталы аша җибәргәндә, гариза бирүчеләр гаризага гади электрон имза салалар.

Гади электрон имза алу өчен, гариза бирүчегә «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» (алга таба – ЕСИА) федераль дәүләт мәгълүмат системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук исәпкә алуны стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр расларга кирәк.

Гаризаны Республика порталы аша биргәндә, гариза бирүче документларның электрон образларын яисә, 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китереп, мондый документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затлар тарафыннан электрон имза белән имзаланган документларны электрон рәвештә тапшыра.

Гаризага, шул исәптән ышаныч кәгазьләренә беркетелгән электрон документлар файл рәвешендә pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf, sig форматларында 50 Мбайт тан артмаган зурлыкта җибәрелә. Тапшырыла торган электрон документларның сыйфаты документ текстын тулысынча укырга һәм документ реквизитларын таныргa мөмкинлек бирергә тиеш.

Гариза бирүченең шәхесен билгеләү шәхсән кабул итү барышында Россия Федерациясе гражданы паспортын яисә шәхесен раслый торган башка документны күрсәтү юлы белән, Россия Федерациясе законнары нигезендә яисә идентификация

һәм аутентификация ярдәмендә Комитетта, КФҮдә, «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны саклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль законның $14^1$ статьясындагы 18 өлешендә каралган мәгълүмат технологияләрен кулланып гамәлгә ашырыла.

2.6.2. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алына торган белешмәләр:

1) салым органында (Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә) исәпкә кую турында белешмәләр.

Документларны алу ысуллары һәм гариза бирүче бирергә хокуклы булган документларны тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.6.1 пункты белән билгеләнгән.

Гариза бирүче гариза биргәндә, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек аша алырга мөмкин булган документларны мондый документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затларның көчәйтелгән квалификацияле имзалары белән расланган электрон документлар рәвешендә мөстәкыйль тапшырырга хокуклы.

Гариза бирүче тарафыннан күрсәтелгән документларны тапшырмау гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) гариза вәкаләтләренә дәүләт хезмәте күрсәтү керми торган дәүләт хакимияте органына тапшырылган;

2) гариза формасында, шул исәптән, Республика порталында гаризаның интерактив формасында кырларны тулысынча тутырмау;

3) тапшырылган документлар дәүләт хезмәте сорап мөрәҗәгать иткән вакытка үз көчләрен югалткан (шәхесне раслый торган документ; Гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ, дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап күрсәтелгән зат мөрәҗәгать иткән очракта);

4) кәгазьдә тапшырылган документларда Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә расланмаган тәртиптә текстта бетерү һәм төзәтү бар;

5) электрон рәвештә тапшырылган документларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә кулланырга мөмкинлек бирми торган зыяннар бар;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар электрон формада, аларны бирү форматына карата таләпләрне бозып тапшырылган һәм (яки) укылмый;

7) 63-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясында билгеләнгән көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаның чынлыгын тану шартларын үтәмәү ачыкланган.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

Акчалата бүләкләүне бирүдән баш тарту өчен нигез булып, агымдагы финанс елында бюджет йөкләмәләре лимитларының акчалата бүләкләү түләү өчен җитмәве тора.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, гариза бирүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты

Гариза бирүчене кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре өчен дәүләт хезмәте күрсәтүгә чират билгеләнмәгән.

2.11. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризасын теркәү вакыты

Гариза кергән көнне.

Электрон рәвештә ял (бәйрәм) көнендә кергән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килә торган эш көнендә теркәлә.

Гариза бирүче яисә аның вәкиле тарафыннан КФҮ аша бирелгән гариза Комитет тарафыннан билгеләнгән тәртиптә КФҮдән кергән көнне теркәлә.

Республика порталына электрон рәвештә кергән гариза, техник мөмкинлек булганда, Республика порталында гаризаларны автомат рәвештә теркәү булмаган очракта, кергән көнне Комитет тарафыннан билгеләнгән тәртиптә теркәлә.

2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган бинада һәм бүлмәләрдә башкарыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. Көтү залларында (урынында) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге һәм аларны тутыру үрнәкләре белән мәгълүмати стендлар урнаштырыла.

Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озатып йөртүче этләрдән файдаланучыларга, бинадан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:

биналарга һәм бүлмәләргә, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләргә каршылыксыз керү шартлары;

территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, биналарга һәм бүлмәгә керү һәм чыгу, транспорт чарасына, шул исәптән кресло-коляска кулланып утырту һәм аннан төшерү мөмкинлеге;

күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе нык бозылган инвалидларны биналарда һәм бүлмәләрдә озатып йөрү һәм аларга ярдәм күрсәтү;

инвалидларның бинага, бүлмәләргә һәм хезмәтләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөртү чыганакларын, аларның

тормыш эшчәнлегенең чикләнгәнлеген исәпкә алып урнаштыру;

инвалидлар өчен кирәкле тавыш белән һәм күреп кабул ителә торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны Брайль рельефлы-нокталы шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемне кертү;

йөртүче этне махсус укытуны раслый торган һәм «Йөртүче этне махсус укытуны раслый торган документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында» Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә тапшырыла торган документы булганда бинага һәм бүлмәгә кертергә рөхсәт итү;

Комитетның, КФҮнең парковкасында I, II төркем инвалидлары идарә итә торган транспорт чараларын һәм мондый инвалидларны һәм (яки) инвалид балаларны йөртә торган транспорт чараларын түләүсез куеп тору өчен урыннарның кимендә 10 проценты (ләкин бер урыннан да ким булмаган күләмдә) бүлеп бирелә. Әлеге пунктта күрсәтелгән парковка урыннарын, юл хәрәкәте кагыйдәләре белән каралган очраклардан тыш, башка транспорт чаралары биләмәскә тиеш;

Комитетның хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтүгә комачаулаучы каршылыкларны җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.

2.13. Дәүләт хезмәтенең үтемлелеге һәм сыйфаты күрсәткечләре.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемлелеге күрсәткечләренә түбәндәгеләр керә:

биналарының җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкин булган зонада урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итә торган бүлмәләрнең җитәрлек санда булуы;

мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Комитетның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтүнең ысуллары, тәртибе, вакыты турында тулы мәгълүмат булу;

гаризаны электрон рәвештә бирү мөмкинлеге;

инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәттән файдаланырга комачаулый торган, инвалидлар өчен биналардан файдалану уңайлылыгын тәэмин итүгә бәйле булмаган башка каршылыкларны җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты күрсәткечләренә түбәндәгеләр керә:

документларны кабул итү һәм карау вакытын үтәү;

дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу вакытын үтәү;

Комитет белгечләре тарафыннан әлеге Регламентны бозуга карата прецедентларның (нигезләнгән шикаятьләрнең) булмавы;

гариза бирүченең Комитет белгечләре белән хезмәттәшлеге саны:

турыдан-туры дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны тапшырганда – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә, шул исәптән электрон почта аша да, бердән артык түгел.

КФҮдә дәүләт хезмәте күрсәткәндә, консультация бирүне, документлар кабул итү һәм бирүне КФҮ белгече башкара.

Гариза бирүче КФҮгә мөрәҗәгать иткәндә, гариза һәм документларны гаризаны теркәү көненнән алып бер эш көне эчендә Комитетка тапшыру тәэмин ителә.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, Комитет белән КФҮнең үзара хезмәттәшлеге тәртибе Комитет белән КФҮ арасында төзелә торган килешү белән, ә КФҮнең гариза бирүчеләр белән хезмәттәшлек тәртибе – КФҮнең эш регламенты белән җайга салына.

Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелә, комплекслы сорату составында күрсәтелми.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан Комитетта, Республика порталында шәхси кабинетта, КФҮдә алынырга мөмкин.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә, шул исәптән күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә ала торган; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте хакында белешмәләр бирү турында башка таләпләр.

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.2. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланыла.

2.14.3. КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәткәндә, консультация бирүне, документлар кабул итү һәм бирүне КФҮ белгече башкара.

Гариза бирүче КФҮ аша мөрәҗәгать иткәндә, гариза һәм документларны гаризаны теркәү көненнән алып бер эш көне эчендә Комитетка тапшыру тәэмин ителә.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, Комитет белән КФҮнең үзара хезмәттәшлеге тәртибе Комитет белән КФҮ арасында төзелә торган килешү белән, ә КФҮнең гариза бирүчеләр белән хезмәттәшлек тәртибе – КФҮнең эш регламенты белән җайга салына.

2.14.4. Гариза бирүче гаризаны электрон документ формасында җибәрә ала, аны рәсмиләштерү тәртибе «Дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәк булган гаризаларны һәм башка документларны электрон документлар рәвешендә рәсмиләштерү һәм тапшыру тәртибе турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 7 июлендәге 553 номерлы карары белән билгеләнгән һәм ул төгәл бер мәгънәле һәм яшерен мәгълүмат, шулай ук электрон рәвештә арадаш хәбәрләр һәм җавап мәгълүматлары җибәрү һәм алу мөмкинлеген тәэмин итә торган гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрләрне, шул исәптән «Интернет» челтәрен, Республика порталын да кертеп файдаланып, шул исәптән 63-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртиптә гади электрон имза кулланып тапшырыла.

Комитетка, Республика порталыннан файдаланып, электрон документ рәвешендә кергән гаризаны теркәү, гариза бирүчегә аның гаризасын алу турында мәгълүматны үз эченә алган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны

Комитетка тапшыру датасын күрсәтеп, электрон рәвештә хәбәрнамә формалаштыру һәм җибәрү Комитетка гариза кергән көнне автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

2.14.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү, аларны рәсмиләштерүнең дөреслеген тикшерү, аларны теркәү, карау, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында карар кабул итү әлеге Регламентның 3.6 – 3.8 пунктлары нигезендә башкарыла.

2.14.6. Гариза бирүчегә бирелә торган дәүләт хезмәте турында мәгълүматны Республика Порталында, Бердәм порталда алу мөмкинлеге бирелә.

Татарстан Республикасы Дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат мәгълүмати стендларда һәм Комитетның рәсми сайтында урнаштырыла.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү вакытлары

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү вариантлары, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда һәм төзелгән реестр язмаларында җибәрелгән басмадагы хаталарны һәм хаталарны төзәтү өчен кирәкле дәүләт хезмәте күрсәтү вариантлары исемлеге.

Дәүләт хезмәте, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда һәм төзелгән реестр язмаларында җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтү бердәм вариантта башкарыла һәм дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары, гариза бирүчеләр категорияләре, түләү күләме һәм тәртибе, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге белән; дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә барлыкка килгән документлар һәм юридик яктан әһәмиятле гамәлләр белән аерылып торган дәүләт хезмәте күрсәтүнең аерым сценарийлары юк.

3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча бирелгән документның дубликатын бирү вариантлары исемлеге, шул исәптән мондый дубликат бирүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләре буенча документ дубликатын бирү бердәм вариантта башкарыла һәм бирү сроклары, гариза бирүчеләр категорияләре, түләү күләме һәм тәртибе, дубликат бирү өчен кирәкле документлар исемлеге белән; дубликат бирү нәтиҗәсендә барлыкка килгән документлар һәм юридик яктан әһәмиятле гамәлләр белән аерылып торган сценарийлары юк.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча гариза бирүчегә бирелгән документның дубликатын бирүдән баш тарту өчен нигез юк.

3.3. Гариза бирүчене профильләштерүнең административ процедурасы тасвирламасы.

Гариза бирүчене профильләштерү процедурасы башкарылмый.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдәге гамәлләр тәртибен тасвирлау

Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә шул исәптән гариза язу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтү;

2) акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү (түләүдән баш тарту);

а) гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

б) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратуларны

формалаштыру һәм җибәрү;

в) акчалата бүләкләүне билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) карар кабул итү;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен җибәрү;

д) акчалата бүләкләү түләү;

3) техник хатаны төзәтү:

а) техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итү һәм теркәү (әлеге Регламентка 4 нче кушымта);

б) акчалата бүләкләүне билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар әзерләү;

в) акчалата бүләкләүне билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) карар җибәрү;

4) акчалата бүләкләүне билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) карар дубликатын әзерләү, бирү;

а) акча бүләкләүне билгеләү һәм түләү (түләүдән баш тарту турында) карар дубликатын бирү хакында гариза кабул итү һәм теркәү (әлеге Регламентка 5 нче кушымта);

б) акчалата бүләкләүне билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) карар дубликатын әзерләү;

в) акчалата бүләкләүне билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) карар дубликатын гариза бирүчегә тапшыру.

3.5. Гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза язу өлешендә ярдәм күрсәтү;

Гариза бирүче Бүлеккә шәхсән, телефон һәм (яки) почта аша (шул исәптән электрон) дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече гариза бирүчегә, шул исәптән, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен документлар формасы һәм башка мәсьәләләр буенча консультация бирә. Бүлек белгече, кирәк булганда, гариза бирүчегә шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм итә.

Гариза бирүче Комитетка шәхсән, телефон аша һәм (яки) электрон почта аша (e-mail: ojm@tatar.ru) электрон хәбәр рәвешендә, почта аша кәгазь чыганакта, Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең Рәсми порталының интернет-кабул итү бүлмәсе аша (http://ojm.tatarstan.ru) дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында, шул исәптән гаризаны рәсмиләштерүдә консультация алу өчен мөрәҗәгать итә.

Гариза бирүче КФҮгә дәүләт хезмәте күрсәтүне алу тәртибе турында консультация алу өчен шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итә ала.

КФҮ хезмәткәре гариза бирүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәтен алу өчен тапшырыла торган документлар составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча хәбәр итә һәм, кирәк булганда, гариза бланкын тутырырга ярдәм итә.

Гариза бирүче КФҮ сайтыннан (http://mfc16.tatarstan.ru/) ирекле файдалану юлы белән дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат ала ала.

Шулай ук Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм вакыты турында

Республика порталында, Бердәм порталда консультация алырга хокуклы.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтү.

3.6. Акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү (түләүдән баш тарту).

3.6.1. Гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү.

1. Гариза Комитетка шәхсән, ышанычлы зат, почта, электрон почта, Республика порталы, КФҮ аша тапшырылырга мөмкин.

Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирә һәм документларны әлеге Регламентның 2.6.1 пункты нигезендә тапшыра.

2. Әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документларны Республика порталы аша җибәргәндә, гариза бирүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

Республика порталында авторизация үтә;

Республика порталында электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яисә документларның электрон образларын (кирәк булганда) электрон гариза формасына беркетә;

электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтүнең шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга куя);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамганы куя);

тутырылган электрон гариза җибәрә (электрон гариза формасында тиешле төймәгә баса);

электрон гариза, 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) таләпләренә туры китереп (гади электрон имза һәм (яисә) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән) имзалана;

электрон гариза җибәрү турында хәбәрнамә ала.

3. Гариза КФҮ аша тапшырылган очракта, гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү турында язмача гариза бирә һәм әлеге Регламентның 2.6 пункты нигезендә КФҮгә документлар тапшыра.

Гаризалар кабул итүче КФҮ хезмәткәре КФҮнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

КФҮ белгече гариза бирүченең кабул ителгән һәм теркәлгән документларын КФҮ эше Регламентында билгеләнгән тәртиптә Комитетка җибәрә. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, Комитет белән КФҮнең үзара хезмәттәшлеге тәртибе Комитет белән КФҮ арасында төзелә торган килешү белән, ә КФҮнең гариза бирүчеләр белән хезмәттәшлек тәртибе – КФҮнең эш регламенты белән җайга салына.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнә торган процедуралар КФҮнең эш регламенты, Комитет белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешү белән билгеләнгән вакытта, ләкин КФҮдә гаризаны теркәгәннең икенче эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе булып, Комитетка җибәрелгән гариза һәм документлар тора.

4. Гариза бирүченең кергән документлар пакетын теркәгәндә, Бүлек белгече түбәндәгеләрне башкара:

гаризаны кабул итү һәм теркәү;

кергән документларны, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан электрон формада кушып бирелгән документларны һәм документларның электрон образларын өйрәнә;

электрон документ образларының комплектлылыгын, укылуын тикшерә;

Республика порталына мөрәҗәгать итеп, электрон имзаның чынбарлык шартлары үтәлешен тикшерә (гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган документларның электрон образлары тапшырылган очракта);

гариза бирүче вәкаләт биргән зат буларак эш итүче гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерү;

әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документларның булу-булмавын тикшерү;

документларны кабул итү датасы, бирелгән керү номеры турында тамга белән гариза күчермәсен гариза бирүчегә почта аша яисә электрон почта аша (аның теләге буенча) җибәрү.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, Бүлек белгече гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булу турында хәбәр итә һәм, документларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен аңлатып, аңа документларны кире кайтара (әлеге Регламентка 6 нчы кушымта нигезендә).

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булмаган очракта, Бүлек белгече Акчалата бүләкләү түләү турындагы гаризаларны теркәү журналына (алга таба – Журнал) мәгълүматлар кертә.

Журналда түбәндәгеләр күрсәтелә:

гариза бирүче тарафыннан документлар тапшыру датасы (Комитетка документлар керү датасы);

гариза бирүченең исеме;

документларны кабул иткән структур бүлекчәнең вазыйфаи затының фамилиясе һәм инициаллары;

объектның исеме һәм кергән документларның (папкалар, тартмаларның һ. б.) исемлеге;

акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү турында карар кабул итү датасы;

акчалата бүләкне билгеләү һәм түләү турында карар хакында гариза бирүчегә хәбәрнамә җибәрү датасы (почта белән җибәрү датасы);

Журнал әлеге Регламентка 7 нче кушымта нигезендә кулъязма һәм электрон

формаларда алып барыла.

Әлеге Регламентта күрсәтелгән процедураны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автоматлаштырылган режимда гамәлгә ашырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура Комитетта гариза һәм документларны теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кабул ителгән һәм теркәлгән документлар.

3.6.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратуларны формалаштыру һәм җибәрү.

1. Сорату җибәрү өчен гариза бирүченең теркәлгән гаризасы нигез булып тора.

Ведомствоара соратулар җибәрү өчен җаваплы Бүлек белгече Регламентның 2.6.3 пунктында каралган документларны һәм белешмәләрне бирү турында соратулар әзерли һәм җибәрә (шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып).

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен соратыла торган документлар:

салым органында исәпкә кую турында белешмәләр Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән соратыла.

Ведомствоара мәгълүмати сорату, гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында, күрсәтелгән органнарга җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында ведомствоара сорату.

2. Ведомствоара соратулар буенча Регламентның 2.6.3 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган мәгълүматлар) бу документлар электрон формада алар карамагында булган органнар тарафыннан «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кагыйдәләре, шул исәптән Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне оештыруның тәкъдим ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә тиешле ведомствоара сорату җибәрелгәннән соң 48 сәгатьтән дә соңга калмыйча бирелә.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазьдә башкарылырга мөмкин:

1) соратыла торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә электрон ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра алмаганда;

2) ведомствоара сорату җибәргәндә, кәгазьдә документларның төп нөсхәсен тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, Регламентның 2.6.3 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган мәгълүматлар) әлеге документлар алар карамагында булган органнар

тарафыннан бирелә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 72 статьясындагы 3 өлеше нигезендә ведомствоара соратуларга җавап әзерләү һәм җибәрү вакыты ведомствоара сорату кергән көннән биш эш көненнән артып китә алмый.

Процедураның нәтиҗәсе: ведомствоара соратулар җибәрү өчен җаваплы Бүлек белгеченә җибәрелгән сорала торган документларны (аларның күчермәләрен яки андагы белешмәләрне) яки баш тарту турында хәбәрнамәне алу.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай законнарны һәм гариза бирүченең хокукларын бозуга юл куймый торган карарлар кабул итү тора.

3.6.3. Акчалата бүләкләүне билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) карар кабул итү.

1. Бүлек белгече гариза бирүче тарафыннан акчалата бүләк алу өчен тапшырылган документлар пакетын формалаштыра һәм Комиссиягә тапшыра. Процедураларның нәтиҗәсе: формалаштырылган һәм Комиссиягә карап тикшерүгә җибәрелгән документлар пакеты.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә башкарыла.

2. Гариза бирүче тарафыннан әлеге Регламентның 2.6.1 пункты нигезендә тапшырылган документлар, әлеге Регламентның 3.6.2 пункты нигезендә алынган белешмәләр (документлар) нигезендә Комиссия акчалата бүләкләү түләү өчен нигезнең булуы яки булмавы турында карар кабул итә. Түләүдән баш тарту турындагы карар әлеге Регламентның 2.8 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән нигез булганда Комиссия тарафыннан кабул ителә.

Комиссия утырышлары Комиссия рәисе карары буенча кирәк булганда, ләкин кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә. Комиссия утырышында Комиссия әгъзаларының кимендә 50 проценты катнашса, Комиссия утырышы хокуклы санала. Комиссия составы, акчалата бүләкләү түләү турында (түләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен тапшырыла торган документларны кабул итү һәм эшләү тәртибе Комитет боерыгы белән раслана.

Комиссия утырышында кабул ителгән акчалата бүләкне түләү өчен нигезләр булу яисә булмау турындагы карарлар беркетмә белән рәсмиләштерелә, аны Комиссия әгъзалары имзалый һәм, Комиссия рәисе тарафыннан раслана.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 46 эш көне эчендә башкарыла.

Беркетмәгә Комиссия әгъзалары имза сала һәм, Комиссия утырышы уздырылганнан соң 3 (өч) эш көненнән артмаган вакыт эчендә, Комиссия рәисе тарафыннан раслана.

Процедураның нәтиҗәсе: Комиссия утырышының акчалата бүләкне бирү өчен нигезләр булу яки булмау турында расланган беркетмәсе.

3. Акчалата бүләкне түләү турында (түләүдән баш тарту турында) карар Комиссия утырышы беркетмәсе нигезендә Комитет боерыгы белән рәсмиләштерелә.

Комиссия утырышы беркетмәсе нигезендә Бүлек хезмәткәре түбәндәгеләрне башкара:

акчалата бүләкләүне билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту

турында) Комитетның боерыгы проектын әзерли;

акчалата бүләкләүне билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) Комитетның боерыгы проектын рәсмиләштерә;

Комитет рәисенә (аңа вәкаләтле затка) (алга таба – рәис) имза салырга акчалата бүләкләүне билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) Комитет боерыгы проектын җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Комиссия беркетмәсе расланган көннән алып өч эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: җитәкчегә имза салырга җибәрелгән боерык проекты.

4. Рәис акчалата бүләкне билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) боерыкны раслый һәм имзалый. Имзаланган документ, Комитет рәисенең төп эшчәнлеге буенча боерыкларны теркәү журналында теркәү өчен, Бүлек белгеченә җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура боерык раслауга кергәннән соң ике эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: акчалата бүләкләүне билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) расланган боерык.

3.6.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен җибәрү

Бүлек хезмәткәре, гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен гариза бирүчегә җибәрә.

Гариза бирүче Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, автомат рәвештә гариза бирүченең шәхси кабинетына Комитетның вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның электрон үрнәге җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң ун эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен җибәрү.

3.6.5. Акчалата бүләкләү түләү.

Акчалата бүләкне түләү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетыннан акчаны гариза бирүченең гаризада күрсәтелгән счетына күчерү юлы белән акчалата бүләкне билгеләү һәм түләү турындагы карар нигезендә Комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура, Комиссия тарафыннан акчалата бүләк түләү турында карар кабул ителгәннән соң, 30 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүченең реквизитлары гариза бирүче тарафыннан тапшырылган шәхси счетына акчалата бүләкләү күчерү.

3.7. Техник хатаны төзәтү

Акчалата бүләкләүне билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) карарны яңадан рәсмиләштерү акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү турында карарда җибәрелгән техник хаталарны (язудагы хатаны, басмадагы хатаны, грамматик яки арифметик хаталарны) бетерүгә бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла

Акчалата бүләкләүне билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту

турында) карарны яңадан рәсмиләштерү гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) дәүләт хезмәте нәтиҗәсе буларак бирелгән техник хаталы документ белән теркәлгән гариза нигезендә гамәлгә ашырыла.

1. Бүлек хезмәткәре:

гариза кабул итүне һәм гражданнар мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында техник хатаны төзәтү турында гаризаны теркәүне гамәлгә ашыра;

акчалата бүләкләүне билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) карарны яңадан рәсмиләштерә;

акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) яңадан рәсмиләштерелгән карар проектын Комитет рәисенә имза салырга җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән техник хатаны төзәтү турында гариза, Комитет рәисенә имза салырга җибәрелгән акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) яңадан рәсмиләштерелгән карар проекты.

2. Комитет рәисе акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) яңадан рәсмиләштерелгән карарны раслый, имзалый һәм мөһер белән ышандыра һәм аны Бүлек хезмәткәренә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура, акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) карар проектын имза салырга җибәргән мизгелдән алып бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: акчалата бүләкләүне билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) имза салынган яңадан рәсмиләштерелгән карар.

3. Бүлек хезмәткәре гаризада күрсәтелгән ысул белән гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) акчалата бүләкне билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) яңадан рәсмиләштерелгән карар җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: акчалата бүләкләүне билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) яңадан рәсмиләштерелгән карар җибәрү.

3.8. Акчалата бүләкләүне билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) карар дубликатын әзерләү, бирү.

1. Бүлек белгече түбәндәгеләрне башкара:

гаризаны кабул итү һәм теркәү;

документларны кабул итү датасы турында тамга, бирелгән керү номеры белән гариза күчермәсен гариза бирүчегә тапшыру яки почта аша яисә электрон почта аша (аның теләге буенча) җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән гариза.

2. Бүлек белгече түбәндәгеләрне башкара:

Акчалата бүләкләүне билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту

турында) карар дубликатын әзерли;

акчалата бүләкне билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) карар дубликатын әзерләү хакында Гариза бирүчегә хат проектын әзерли һәм Бүлек башлыгына килештерү өчен җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Бүлек белгеченә башкару өчен гариза җибәргәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына килештерүгә җибәрелгән акчалата бүләкне билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) карарның әзерләнгән дубликаты.

3. Бүлек башлыгы акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) карарның әзерләнгән дубликатының дөреслеген тикшерә, хат проектын килештерә һәм аларны Комитет рәисенә имза салырга җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Бүлек башлыгына акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) карар дубликаты һәм хат проекты килештерүгә кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Комитет рәисенә имза салырга җибәрелгән акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) карар дубликаты һәм хат проекты.

4. Комитет рәисе акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) кушып бирелә торган карар дубликаты белән хат проектын имзалый һәм Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура Бүлек башлыгыннан хат проекты кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: акчалата бүләкләүне билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) имза салынган хат проекты, карар дубликаты.

5. Бүлек белгече дәүләт хезмәте күрсәтү турында Комитет рәисе имзалаган хатны теркәүне гамәлгә ашыра, ул акчалата бүләкләүне билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) карар дубликаты белән бергә гариза бирүчегә яки аның ышанычлы кешесенә (ышаныч кәгазе булганда) расписка белән тапшырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза бирүче яки аның ышанычлы заты килгәннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла. КФҮ аша гариза биргән очракта, әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура, гариза бирүче килгән көнне, КФҮ эше Регламенты белән билгеләнгән вакытта, чират тәртибендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: акчалата бүләкләүне билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) гариза бирүчегә тапшырылган хат һәм карар дубликаты.

## 4. Административ регламентның үтәлешен тикшереп тору формалары

4.1. Җаваплы вазыйфаи затларның әлеге Регламент нигезләмәләрен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларны башкаруын, шулай ук җаваплы затлар тарафыннан карарлар кабул итүне агымдагы контрольдә тоту Бүлек башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.2. Административ регламентның үтәлешен контрольдә тоту тикшерүләр үткәрүне, дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр булган мөрәҗәгатьләрне карау, карарлар кабул итү һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формаларына түбәндәге тикшерүләрне үткәрү керә:

эш башкаруны алып бару;

документларны карау нәтиҗәләренең законнар (әлеге Регламент) таләпләренә туры килүе;

документларны кабул итү вакытын һәм тәртибен үтәү;

дәүләт хезмәте күрсәткәндә нәтиҗәләр бирү вакытын һәм тәртибен үтәү.

Тикшерүләр үткәрү периодлылыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга ия (гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча).

4.3. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланганда, гаепле дип танылган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Административ регламентны башкаруны гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәткәндә Комитет эшчәнлегенең ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1[1] өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, эшчеләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Гариза бирүчеләр Комитетның, Комитетның вазыйфаи затының яисә Комитетның дәүләт граждан хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) Комитетка шикаять бирергә хокуклы. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә Комитет карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

КФҮ хезмәткәрләренең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр КФҮ җитәкчесенә бирелә, КФҮнең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр КФҮне гамәлгә куючыга бирелә.

5.2. Гариза бирүче шул исәптән түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында соратуны, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15[1] статьясында күрсәтелгән соратуны теркәү вакытын бозу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозу;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документларны яки мәгълүматны бирүне яисә гамәлләр башкаруны таләп итү;

4) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында тапшыру каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуның нигезләре каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) Комитетның, аның вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда алар тарафыннан җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы йә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозу;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) Федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торуның нигезләре каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору;

10) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәткәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда яисә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәткәндә аларның булмавы һәм (яки) дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документлар яисә мәгълүмат таләп итү.

5.3. Шикаять язмача кәгазьдә яки электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, Комитетның рәсми сайты (http://ojm.tatarstan.ru), Республика порталы (http://uslugi.tatarstan.ru), Бердәм портал (http://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә алынырга мөмкин.

КФҮ, КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта аша, «Интернет» челтәрен, КФҮнең рәсми сайтын (http://mfc16.tatarstan.ru/), Республика порталын, Бердәм порталны кулланып җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә алынырга мөмкин.

5.4. Шикаять түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган Комитетның, Комитетның вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең, КФҮнең, аның җитәкчесенең яисә хезмәткәренең исеме;

гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган

очракта), яшәү урыны турындагы белешмәләр яки гариза бирүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номер(-лар)ы, гариза бирүчегә җавап юлланырга тиешле электрон почта адрес(-лар)ы (булган очракта) һәм почта адресы;

Комитетның, аның вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең шикаять бирелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

Комитетның, аның вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең карары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән гариза бирүче килешми торган дәлилләр.

5.5. Гариза бирүче тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булганда), йә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаять аның кергән көненнән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлергә тиеш. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгәннән соң 15 эш көне эчендә. Комитетның, Комитетның вазыйфаи затының, КФҮнең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы $1^1$ өлешендә каралган оешмаларның гариза бирүчедән документларны кабул итүдән йә җибәрелгән басмадагы хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына карата яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта шикаять белдерелгән очракта – аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басмадагы хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән түләү алу каралмаган очракларда алынган акчаны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүче теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә җавапта, дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында, Комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм гариза бирүчегә дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында башкарырга кирәк булган алдагы гамәлләре турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип табылган очракта, гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга карата шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат китерелә.

5.8. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча

административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү буенча вәкаләтле вазыйфаи зат, хезмәткәр, булган материалларны, кичекмәстән, прокуратура органнарына җибәрә.

5.9. Комитет карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), шулай ук аның вазыйфаи затларына, йә дәүләт хезмәткәрләренә карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү белән бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җайга салына.

Тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Форма

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

Приказ | Казан шәһәре | Боерык

__________ № ___- од

Акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү турында карар

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1995 елның 05 августындагы 545 номерлы карары белән расланган Тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган корал, хәрби кирәк-яраклар, корал патроннары, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләр ирекле рәвештә тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләр түләү эшен оештыру турындагы нигезләмәгә ярашлы рәвештә һәм Рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралларны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү түләүне оештыру комиссиясенең ______________________ бәяләмәсе нигезендә боерам:

Рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралларны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданинга ____________________________________________________________
(Ф.И.А. (соңгысы – булганда))
_______________ сум күләмендә акчалата бүләкләү билгеләргә һәм түләргә,

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе ________________________
(Ф.И.А. (соңгысы – булганда))

Тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Форма

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

Приказ Казан шәһәре Боерык

__________ № ___- од

Акчалата бүләкләү түләүдән баш тарту турында карар

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1995 елның 05 августындагы 545 номерлы карары белән расланган Тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган корал, хәрби кирәк-яраклар, корал патроннары, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләр ирекле рәвештә тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләр түләү эшен оештыру турындагы нигезләмәгә ярашлы рәвештә һәм Рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралларны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү түләүне оештыру комиссиясенең ______________________ бәяләмәсе нигезендә боерам:

Рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралларны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданга

____________________________________________________________

(Ф.И.А. (соңгысы – булганда))

акчалата бүләкләү түләүне кире кагарга.

Баш тарту сәбәбе: ____________________________________________________

Татарстан Республикасы Биологик
ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе ________________________

(Ф.И.А. (соңгысы – булганда))

Тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына
кемнән ______________________________

_____________________________________,
(Ф.И.А. (соңгысы – булганда))
яшәү (теркәлү) адресы:
_____________________________________
_____________________________________
Чынлыкта яшәү адресы:
_____________________________________
_____________________________________
паспорт: серия _________ номер _____________
бирелгән «___»____________________________

Акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү турында гариза

Ихтыяри тапшырылган корал өчен миңа акчалата бүләк түләүне билгеләвегезне сорыйм ____________________________________________________________
(коралның, сугыш кирәк-яракларының, коралга патроннарның, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләрнең атамасы)
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
(корал, сугыш кирәк-яраклары, коралга патроннар, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләр кабул итү квитанциясенең номеры һәм дата)

Гаризага түбәндәге документлар беркетелә:
1) ____________________________________________________________________
2) ____________________________________________________________________
3) ____________________________________________________________________
4) ____________________________________________________________________
5) ___________________________________________________________________.

Акчалата бүләкне билгеләү һәм түләү турында карарны түбәндәгечә алырга риза:
электрон документны E-mail адресына ______________________________,
расланган күчермә рәвешендә кәгазьдә почта аша ____________________________________ адресы буенча җибәреп,
башка юл белән ______________________________________________.

Моның белән раслыйм: гаризага кертелгән минем шәхесемә һәм мин тәкъдим иткән затка кагылышлы мәгълүматлар, шулай ук түбәндә мин керткән мәгълүматлар дөрес. Гаризага беркетелгән документлар (документлар күчермәләре) гариза биргән вакытта Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза тапшырылган вакытта бу документлар гамәлдә һәм алардагы мәгълүматлар ышанычлы.

Миңа күрсәтелгән дәүләт хезмәтенең сыйфатын бәяләү буенча _________ телефоны аша сораштыруда катнашырга ризалыгымны бирәм.

| ____________ | ______________________ | ______________________________ |
|---|---|---|
| (дата) | (гариза бирүченең<br>(вәкаләтле вәкилнең) имзасы) | (Ф.И.А. (соңгысы – булганда)) |

Тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына
кемнән
______________________________________,
______________________________________,
(Ф.И.А. (соңгысы – булганда))
яшәү (теркәлү) адресы:
______________________________________
______________________________________
Чынлыкта яшәү адресы:
______________________________________
______________________________________
паспорт: серия _________ номер _____________
бирелгән «___»______________________________

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Мин, ____________________________________________ __________________
(Гариза бирүченең (вәкаләтле вәкилнең) Ф.И.А. (соңгысы – булганда) тулысынча күрсәтелә)
яшәү адресы ________________________________________________________________
____________________________________________________
______________________________________________________________________________
(индексын күрсәтеп, гариза бирүченең почта адресы, телефоны, электрон адрес)
______________________________________________________________________________
дәүләт хезмәте күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм
________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________.
(хезмәтнең исеме)
Язылган: __________________________________________________________________
Дөрес мәгълүматлар: ___________________________________________________
______________________________________________________________________________
Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегезне сорыйм.
Түбәндәге документларны терким:

1.______________________________

2.______________________________

Техник хатаны төзәтү турында мәгълүматны түбәндәгечә җибәрүегезне сорыйм:
электрон документны E-mail адресына ______________________________,
расланган күчермә рәвешендә кәгазьдә почта аша ______________________________ адресына,
башка юл белән ______________________________.

Моның белән раслыйм: гаризага кертелгән минем шәхесемә һәм мин тәкъдим иткән затка кагылышлы мәгълүматлар, шулай ук түбәндә мин керткән мәгълүматлар дөрес. Гаризага беркетелгән документлар (документлар күчермәләре) гариза биргән вакытта Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза тапшырылган вакытта бу документлар гамәлдә һәм алардагы мәгълүматлар ышанычлы.

Миңа күрсәтелгән дәүләт хезмәтенең сыйфатын бәяләү буенча __________ телефоны аша сораштыруда катнашырга ризалыгымны бирәм.

| ______________ | ______________________________ | ______________________________ |
|---|---|---|
| (дата) | (гариза бирүче (вәкаләтле вәкил) имзасы) | (Ф.И.А. (соңгысы – булганда)) |

Тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына
кемнән

_______________________________________,
(Ф.И.А. (соңгысы – булганда))
яшәү (теркәлү) адресы:
_______________________________________
_______________________________________
Чынлыкта яшәү адресы:
_______________________________________
_______________________________________
паспорт: серия _________ номер _____________
бирелгән «___»______________________________

Үз ихтыярым белән рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралларны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне тапшырган өчен акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү (түләүдән баш тарту турында) турындагы карар дубликатын бирү турында гариза

Үз ихтыярым белән рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралларны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне тапшырган өчен акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү (түләүдән баш тарту турында) турындагы карар дубликатын бирүегезне сорыйм.

Үз ихтыярым белән рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралларны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне тапшырган өчен акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү (түләүдән баш тарту турында) турындагы карар реквизитлары (датасы, номеры): ________________________________________________________________

Үз ихтыярым белән рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралларны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне тапшырган

өчен акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү (түләүдән баш тарту турында) турындагы карар дубликатын бирү кирәклеге түбәндәге хәлләргә нигезләнә: ______________________________________________________________________

Үз ихтыярым белән рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралларны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне тапшырган өчен акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү (түләүдән баш тарту турында) турындагы карар дубликатын кәгазьдә яисә электрон документ рәвешендә әзерләвегезне сорыйм. (кирәкмәгәнен сызып атарга)

Акчалата бүләкне билгеләү һәм түләү турында карарны түбәндәгечә алырга риза:

электрон документны E-mail адресына ______________________________________,

расланган күчермә рәвешендә кәгазьдә почта аша _______________________________________________________________ адресына,

башка юл белән _____________________________________________________________

.

______________________ ________________________________________

(имза) (Ф.И.А. (соңгысы – булганда))

«____»_______________________20__ ел

Тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

Форма

Документларны кабул итүдән баш тарту турында хәбәрнамә

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитет ____________________________________________

(физик затның Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)),

______________________________________________________________

паспорт мәгълүматлары, теркәлү адресы)

______________________________________________________________

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документлар кабул итүдән баш тарту турында хәбәр итә

______________________________________________________________

(дәүләт хезмәте атамасы)

Баш тарту сәбәбе: ____________________________________________

____________________ ______________ ______________________________

(вазыйфасы) (имза) (Ф.И.А. (соңгысы – булганда))

Тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 7 нче кушымта

Форма

Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турында гаризаларны теркәү журналы

| т/б № | Гариза бирүче тарафыннан документлар тапшыру датасы (Комитетта документларны теркәү датасы) | Гариза бирүченең исеме | Документларны кабул иткән структур бүлекчәнең вазыйфаи затының фамилиясе һәм инициаллары | Объектның исеме һәм кергән документларның (папкалар, тартмаларның һ. б.) исемлеге | Акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү турында карар кабул итү датасы | Акчалата бүләкне билгеләү һәм түләү турында карар хакында гариза бирүчегә хәбәрнамә җибәрү датасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| … | | | | | | | |

Тиешле рөхсәтсез саклана торган яки Татарстан Республикасы территориясендә табылган коралны, хәрби кирәк-яракларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз ихтыяры белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләкләү билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмә)

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның реквизитлары

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Рәис | 211-66-94 | ojm@tatar.ru |
| Рәис урынбасары | 211-75-06 | Matveev.Yuriy@tatar.ru |
| Идарә башлыгы | 211-71-89 | Radik.Mutaharov@tatar.ru |
| Финанс исәбе һәм дәүләт сатып алулары бүлеге башлыгы | 211-68-04 | Gulnaz.Sabirova@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Җир асты байлыкларыннан, табигый ресурслардан файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре бүлеге башлыгы | 264-77-78 | Marat.Fashutdinov@tatar.ru |